# Проект эшебез рус мәктәпләрендә рус балалары белән эшләүче татар теле һәм әдәбияты укытучыларына багышлана.

Проектны әзерләде:
Рамазанова Р.Г.
Биектау районы
Коркачык урта мәктәбенең
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Проектның төп максатлары:** рус телле укучыларга татар мәкальләрен өйрәтү алымнарын ачыклау, татар халык мәкальләренә кызыксыну уяту.

- **Проектның тикшерү объекты:** рус телле балалар белем алган дәреслекләр, аларда татар халык мәкальләренең бирелеше, аларның үзенчәлекләре.

- **Проектның фәнни яктан әһәмияте.**

Рус телле укучылар белән эшләүче укытучыларга проектта күтәрелгән темаларга күзәтү ясауның әһәмияте зур булыр дип саныйбыз.

- **Проектның практик әһәмияте һәм яңалыгы:** рус балалары белән эшләүче укытучыларга, кулланма өчен материал була алуында.

- **Проект эшебезнең фәнни – методологик нигезен** Ф.С.Сафиуллина, А.Ш.Әсәдуллин, Ф.Ф.Харисов,Ч.М.Харисова, К.С. Фәтхуллова, Н.Исәнбәт, Х.Ш.Мәхмүт, Х. Ярми хезмәтләре тәшкил итә.

## ПРОЕКТ ЭШЕ
## (ике бүлектән тора)

1) Халык авыз иҗаты үрнәкләрен өйрәнү максатлары.

1)Татар мәкальләрен өйрәтү системасы. Башлангыч мәктәптә мәкальләрне өйрәнү күнегүләре.
2) Гомуми белем мәктәбендә мәкальләрне өйрәтү
күнегүләре.

Татар телен чит тел буларак өйрәткәндә, түбәндәге проектларны кулланабыз:

- мәгълүмати (темага караган мәкальләрне җыю, аларны катнашучыларга тәкъдим итү, алар турында фикер алышу);
- рольле (проект эчтәлегеннән чыгып, укучылар рольләр алалар, бу аларга нәрсәдер әйтергә яки нәрсә турында булса да сорарга өтәргеч бирә);
- иҗади (кичә яки бәйрәм үткәрү өчен сценарий төзү, мәктәп яки күп тиражлы газета өчен мәкальләр язу);

# Мәсәлән, мәкальләр:

- Кеше сүзен тыңла, ... (үз акылың белән эш ит.)
- Ир-егет үзе өчен туа, ... (иле өчен үлә.)
- Кем эшләми, ...(шул ашамый .)
- Акыллы сүзен ... (мин дип башламый.)
- Үзе әдәпсез, ... (киеме сәдәпсез.)
- Һәр ялтыраган ... (алтын түгел.)
- Бөтен халык берьюлы суласа, ... (давыл кубар.) h.б.

Мәсәлән, *бәхет күктә булмый, кулда була - счастье - не в небесах ,а в руках; дуслык ашаганда беленми, эшләгәндә беленә - дружба познается не за обедом,а за делом* һ.б.

- Татарча матур әдәбият әсәрләрен, халык авыз иҗаты үрнәкләрен һ.б. кычкырып сәнгатьле уку 1нче сыйныфта туган телдә авазлар һәм хәрефләрне өйрәнгәч үк башлана һәм югары сыйныфларда да дәвам итә.
- 1 нче сыйныфта әйтелешнең үзенчәлекләрен балаларга күрсәтүдә техник чаралардан файдалану, дәресләрдә төрле уеннар уйнау да уңай нәтиҗәләргә китерә.Алар аваз белән хәрефне аерырга өйрәнәләр; сүз басымы һәм исем, сыйфат, фигыль кебек сүз төркемнәре турында башлангыч мәгълүмат алалар.
- 2 нче сыйныфта авазлар һәм хәрефләр турындагы мәгълүмат тагын да тулыландырыла.Сөйләм телен үстерү, сүз байлыгын арттыру төрле язма эшләр үткәндә вакытта да алып барыла.

## Татар теле дәресләрендә рус телле балалар, шушы телгә хас булган эчке формаларны гамәли үзләштереп, аларны сөйләмдә кулланырга өйрәнәләр.

- 5 нче сыйныф дәреслегеннән күнегүләр.
- Мәкальләрне тәрҗемә итегез.(18нче бит, 4нче күнегү).
- *Иле барның теле бар.
- *Тел -белемнең ачкычы, акылның баскычы.
- 6 нчы сыйныф дәреслегеннән күнегүләр.
- Мәкальләрне тәрҗемә итегез. (22 бит, күнегү 5.)
- *Кеше күрке- йөз,
- Йөзнең күрке күз,
- Уйның күрке- тел,
- Телнең күрке- сүз.
- *Тел- белемнең ачкычы, акылның баскычы.
- * Сүз- бер күнлек, тел- гомерлек.
- * Туган телен кадерләгән халык кадерле булыр.
- * Алтын җирдән табыла, белем- китаптан.

## Йомгаклау.

Рус телле укучыларга татар телен өйрәтү юнәлешендә инде берничә ел эшлибез. Эш барышында түбәндәге максатларга ирешү бурычын куйдык:

- Әдәби тел нормаларын үзләштерү;
- Укучыларның сүз байлыгын арттыру;
- Фикерне төгәл һәм язмача бәйләнешле, төгәл, ачык итеп әйтә белергә өйрәтү.

*Проектны эшләү барышында түбәндәге нәтиҗәләргә килдек:*

1. Татар телен чит тел буларак өйрәтү процессында мәкальләрдән файдалану укучыны белем алуга, укуга дәртләндерә, анда фән белән кызыксыну уята.
2. Гомуми башлангыч белем мәктәбендә татар теле дәресләрендә мәкальләр укучыларның уку һәм сөйләм күнекмәләрен үстерүгә юнәлтелә.
3. Татар теле дәресләрендә укытучының халык авыз иҗаты үрнәкләреннән файдалануы да, аерым алганда, табышмаклар, мәкаль-әйтемнәр, санамышлар ятлау, аларны дәфтәрләргә дөрес һәм матур итеп язып кую да балаларны татарча аңлаешлы, әдәби нормаларга туры килердәй итеп сөйләргә өйрәтүдә зур әһәмияткә ия булып тора.
4. Рус мәкальләре белән охшаш  мәкальләргә килсәк, монда тел һәм төзелеш ягыннан уртаклык юк, әмма мәгънә ягыннан бер үк төсле булганнары шактый күп: ни чәчсәң шуны урырсың. Что посеешь, то и пожнешь.

# Игътибарыгыз өчен рәхмәт!